«РАСЛЫЙМ»

Татарстан Республикасы

мәгариф һәм фән министры

___________ И.Г.Һадиуллин

«23» ноябрь 2020 нче ел

**Рус телендә белем бирү мәктәпләренең
рус телле укучылары өчен 2021 нче елда
туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру
өчен әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр
һәм эчтәлек элементларының кодификаторы**

Татар теленнән төп гомуми белем бирү программасын үзләштергән IX сыйныф укучыларының әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторы - (алга таба – кодификатор) 2021 нче елда дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру өчен эшләнгән үрнәк материалларның эчтәлеген билгеләүче документларның берсе.

Кодификаторда Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән белем бирү программаларына кертелгән эчтәлек элементлары һәм әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр чагылыш таба.

Кодификатор укучыларның татар теленнән коммуникатив компетенциясен (аерым алганда, сөйләм, тел, социаль-мәдәни, уку-танып белү компетенцияләре) дәрәҗәсен ачыклауга юнәлтелгән. Әлеге документ татар теленнән төп гомуми белем бирү мәктәбе курсы буенча имтихан биремнәрен төзү өчен нигез булып тора.

Кодификаторда эчтәлеге киңрәк булган блоклар, калын курсив хәрефләр белән язылып, кечерәк блокларга бүленде. Кодификатордагы әлеге позицияләрнең һәрберсе укыту эчтәлегенең берләштерелгән дидактик берәмлекләрен тәшкил итә. Аларга берничә тематик берәмлек керә ала.

Беренче баганада эчтәлекнең зур блокларына туры килгән бүлек коды бирелгән. Икенче баганада тикшерелә торган элемент кодлары күрсәтелгән. Өченче багана тикшерелә торган материалның эчтәлеген чагылдыра.

## 1 нче бүлек. Төп гомуми белем бирү мәктәбе курсы буенча татар теленнән дәүләт йомгаклау аттестациясендә тикшерелә торган эчтәлек элементлары

Төп гомуми белем бирү мәктәбе курсы буенча татар теленнән дәүләт йомгаклау аттестациясендә тикшерелә торган эчтәлек элементлары исемлеге[1] татар теленнән төп гомуми белем бирү мәктәпләре өчен үрнәк эш программасына нигезләнеп төзелде.

| Бүлек коды | Тикшерелә торган элемент коды | Тикшерелә торган материалның эчтәлеге |
|---|---|---|
| 1 | | ***Тыңлап аңлау*** |
| | 1.1 | Диалогик һәм монологик текстларның төп эчтәлеген тыңлап аңлау. |
| | 1.2 | Диалогик һәм монологик текстларны тыңлап, алардан кирәкле / сорала торган мәгълүматны аңлау һәм табу. |
| **2** | | ***Уку*** |

[1] Татар теленнән төп гомуми белем бирү (5-9 нчы сыйныфлар) баскычында укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр.



19

| | | |
|---|---|---|
| | 2.1 | Татар халкының тормышын, көнкүрешен, мәдәниятен, гомумән, көндәлек тормышны чагылдырган аутентик текстларны уку һәм төп эчтәлеген аңлау. |
| | 2.2 | Укылган тексттан кирәкле мәгълүматны сайлап алу. |
| | 2.3 | Төрле жанрлардагы аутентик һәм адаптацияләнгән текстларның эчтәлеген тулысынча аңлау. |
| **3** | | ***Язу*** |
| | 3.1 | Укучының үзе һәм гамәлләре турында мәгълүмат бирә белүе. |
| | 3.2 | Үрнәк буенча шәхси хат язу. |
| | 3.3 | Татар язуының орфографик нормаларын саклау. |
| | 3.4 | Коммуникатив бурычларны аңлап, җөмләләрне үзгәртеп язу. |
| **4** | | ***Тел материалы*** |
| 4.1 | | *Сөйләмнең грамматик ягы* |
| | 4.1.1. | Җөмләнең коммуникатив төрләре: раслау, инкяр, сорау, боеру, тойгылы җөмләләр һәм аларда сүз тәртибе. |
| | 4.1.2 | Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. |
| | 4.1.3 | Гади һәм кушма җөмләләр. |
| | 4.1.4 | Җөмләнең грамматик кисәкләре. Баш кисәкләр (ия, хәбәр). Иярчен кисәкләр (аергыч, тәмамлык, хәл). |
| | 4.1.5 | Җөмләнең модаль кисәкләре (эндәш сүз, кереш сүз). |
| | 4.1.6 | Җөмләнең тиңдәш кисәкләре, алар янында гомумиләштерүче сүзләр. |
| | 4.1.7 | Җөмләдә сүз тәртибе. |
| | 4.1.8 | Тезмә кушма җөмлә. |
| | 4.1.9 | Иярченле кушма җөмлә. |
| | 4.1.10 | Берлек һәм күплек сандагы исемнәр. |
| | 4.1.11 | Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. |
| | 4.1.12 | Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. |
| | 4.1.13 | Исемнәрнең ясалышы. |
| | 4.1.14 | Алмашлыкларның төркемчәләре. |
| | 4.1.15 | Зат алмашлыкларның килеш белән төрләнеше. |
| | 4.1.16 | Саннарның төркемчәләре. |
| | 4.1.17 | Саннарның ясалышы. |
| | 4.1.18 | Сыйфат дәрәҗәләре. |
| | 4.1.19 | Сыйфатларның ясалышы. |
| | 4.1.20 | Рәвеш. |
| | 4.1.21 | Рәвешләрнең ясалышы. |

| | | |
|---|---|---|
| | 4.1.22 | Затланышлы һәм затланышсыз фигыльләр һәм аларның кулланылышы. |
| | 4.1.23 | Фигыльнең барлык һәм юклык формасы. |
| | 4.1.24 | Фигыльнең заман формалары. |
| | 4.1.25 | Фигыльләрнең ясалышы. |
| | 4.1.25 | Бәйлек һәм бәйлек сүзләр. |
| | 4.1.22 | Модаль сүзләр. |
| | 4.1.23 | Теркәгечләр. |
| | 4.1.24 | Кисәкчәләр. |
| 4.2 | | *Сөйләмнең лексик ягы* |
| | 4.2.1 | Төп гомуми белем бирү мәктәбендә өйрәнелгән аралашу темаларына бәйле лексика. |
| | 4.2.2 | Еш кулланыла торган сөйләм гыйбарәләре. |
| | 4.2.3 | Татар мәдәниятенә караган әдәпле сөйләм үрнәкләре, тотрыклы гыйбарәләр. |
| | 4.2.4 | Алынмалар. Антонимнар. Синонимнар. |

***Сөйләмнең предмет эчтәлеге***

1. Үзем һәм гаиләм турында. Туганлык мөнәсәбәтләре.
2. Көндәлек тормышта аралашу.
3. Көндәлек режим. Буш вакытым.
4. Бәйрәмнәр.Татар һәм рус халыкларының милли бәйрәмнәре һәм йолалары. Котлаулар.
5. Минем яраткан шөгыльләрем һәм уеннарым. Минем дөньям һәм Интернет. Спорт уеннары.
6. Мин һәм минем дусларым. Дуслык.
7. Кешенең тышкы кыяфәте һәм холкы.
8. Мәктәбем һәм сыйныфым. Дәресләр. Түгәрәкләр, спорт секцияләре. Сыйныфташлар белән үзара мөнәсәбәтләр.
9. Һөнәрләр.
10. Өлкәннәргә хөрмәт.
11. Әйләнә-тирә дөнья. Йортым, фатирым. Туган шәһәрем/авылым.
12. Туган як табигате. Табигать һәм кеше. Ел фасыллары. Экология.
13. Татарстан Республикасы. Гомуми мәгълүмат: исеме, башкаласы, шәһәрләре, халкы, елгалары, истәлекле урыннары.
14. Мәдәният, сәнгать.
15. Илләр һәм шәһәрләр.
16. Сәяхәт итү. Җәйге ял. Кышкы ял.
17. Татар халкының күренекле шәхесләре.

## 2 нче бүлек. Дәүләт йомгаклау аттестациясендә укучыларның тикшерелә торган әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр

Бу бүлектә төп гомуми белем бирү мәктәбе курсы буенча чыгарылыш сыйныф укучыларының имтиханда тикшерелә торган әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр исемлеге тәкъдим ителә.

Таләпләр, системалы-эшчәнлекле юнәлешкә нигезләнеп: *1) тыңлап аңлый, укый һәм яза алу; 2) гамәли күнекмәләргә ия булу, 3) белү/аңлау* бүлекләренә куела.

**Тыңлап аңлый, укый һәм яза алу** бүлегендә сөйләм эшчәнлегенең әлеге төрләре буенча укучыларның әзерлеге, шулай ук социаль-мәдәни компетенциясе дә тикшерелә.

**Гамәли күнекмәләргә ия булу** бүлегендә татар теле орфографиясе, орфоэпиясе, грамматикасы һәм лексикасын үзләштерүгә караган таләпләр куела.

**Белү/аңлау бүлегендә** лексик-грамматик материалны һәм социаль-мәдәни мәгълүматны тел материалы буларак үзләштерүгә куелган таләпләр күрсәтелә.

| | **Таләпләр** |
|---|---|
| **1.** | **Тыңлап аңлый, укый һәм яза алу** |
| | Үзең, гаиләң, дусларың, кызыксынуларың һ.б. турында язмача сөйли алу. |
| | Өйрәнелгән темаларга караган вакыйга-күренешләр турында кыскача мәгълүмат бирә алу, тасвирлау. |
| | Үз шәһәрең/авылың, илең, туган телең һ.б. турында кыскача мәгълүмат бирә алу. |
| | Укылган текстка карата үз фикереңне белдерә алу. |
| | Персонажларга кыскача характеристика бирә алу. |
| | Аутентик прагматик текстларның төп эчтәлеген аңлый һәм алардан кирәкле мәгълүматны аерып күрсәтә алу. |
| | Сөйләмнең төрле коммуникатив типларына караган авыр булмаган аутентик текстларда теманы, төп фикерне билгели алу. |
| | Тел тоемлавыннан һәм контексттан файдалана алу. |
| | Тексттан кирәкле мәгълүматны алу өчен, өлешләп укый алу. |
| | Төрле жанрларга караган адаптацияләнгән аутентик текстларның эчтәлеген тулысынча аңлап укый алу. |
| | Текстның төп фактлары арасында логик эзлеклелек урнаштыра алу. |
| | Үрнәк буенча шәхси хат яза алу. |
| | Хатта адресаттан шәхси тормышы турында сорый, үз хәлләреңне хәбәр итә алу. Үтенеч белдерә алу. |
| | Рәхмәт белдерә алу. |
| | Татар сөйләм этикеты үрнәкләрен куллана алу. |
| | Үз халкың турында мәгълүмат бирә алу. |
| | Тексттагы вакыйгаларны аңлау өчен, тел материалыннан һәм контексттан чыгып эш итә алу. |

| | |
|---|---|
| | Синонимнардан файдалана алу. |
| *2* | ***Гамәли күнекмәләргә ия булу*** |
| | Татар теленең төп орфографик кагыйдәләренә бәйле күнекмәләр. |
| | Татар теленең төп орфоэпик закончалыкларына бәйле күнекмәләр. |
| | Җөмләнең коммуникатив төрләрен тану һәм куллану. |
| | Җәенке һәм җыйнак җөмләләрне куллану. |
| | Гади һәм кушма җөмләләрне куллану. |
| | Фигыльләрнең заман формаларын дөрес куллану. |
| | Сан, килеш, тартым кушымчаларын дөрес куллану. |
| | Җөмлә кисәкләрен үзара яраштырып куллану. |
| | Исемнәрне дөрес куллану. |
| | Сыйфатларны дөрес куллану. |
| | Алмашлыкларны дөрес куллану. |
| | Саннарны дөрес куллану. |
| | Рәвешләрне дөрес куллану. |
| | Бәйләгеч һәм модаль сүзләрне дөрес куллану |
| | Татар пунктуациясенә караган кагыйдәләрне белү һәм тыныш билгеләрен дөрес кую. |
| | Башлангыч һәм төп гомуми белем бирү мәктәбендә үзләштерелгән темалар буенча лексик берәмлекләрне дөрес куллану. |
| | Татар сөйләм этикеты үрнәкләрен тану һәм алардан дөрес файдалану. |
| *3* | ***Белү/аңлау*** |
| | Төп гомуми белем бирү мәктәбендә үзләштерелгән лексик берәмлекләрнең мәгънәсен белү/ аңлау. |
| | Татар сөйләменә хас төп грамматик күренешләрне белү/аңлау. |
| | Татар сөйләменә хас төп җөмлә калыпларын белү/ аңлау. |
| | Татар сөйләм этикеты нормаларын белү. |
| | Татар халкының тормышы, көнкүреше, мәдəниятенә хас үзенчәлекләрне белү. |
| | Татар теленең дөньяда тоткан роле турында белү. |